**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен гамәлгә кую турында» Указына үзгәреш кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен гамәлгә кую турында» 1997 елның 11 июлендәге ПУ-359 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 18 августындагы ПУ-313 номерлы, 2017 елның 8 апрелендәге ПУ-297 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 11 июлендәге 484 номерлы, 2024 елның 5 августындагы 592 номерлы, 2025 елның 6 мартындагы 183 номерлы һәм 2025 елның 28 маендагы 420 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), аңа түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$1^1$. А.Е. Арбузовның тууына 150 ел тулу белән бәйле рәвештә, 2027 елда Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен тапшыру 2028 елдан 2027 елга күчерелә, дип билгеләргә.».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2026 ел, 28 август
№ 704